Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының уналтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

27 октябрь, 2021 ел № 111

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына таянып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 25 ноябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.11 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә бәйсез бәя бирү, шулай ук күчемсез мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрү буенча заказчы булып чыгыш ясый.»;

- түбәндәге эчтәлекле 4.1.9 пункт өстәргә:

«4.1.9. Үз бюджет сметасы исәбеннән мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә бәйсез бәя бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәткә һәм җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрү хезмәтләрен финансларга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып (халыкка җиткерергә) чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов